**ГЛАВА МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма, ул.Центральная, 46а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк ур, 46а

Тел./факс: +7(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**27 ноябрь 2023 ел** **№ 4**

## Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлегенең Тимерче авылына гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

25.1 статьясына ярашлы., «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 22 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Уставы һәм "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында" 2019 елның 22 октябрендәге 173 номерлы карарның (Советның 28.04.2020 № 199, 19.11.2020 № 13 карарлары редакциясендә)

**КАРАР ИТӘМ:**

1. 2023 елның 8 декабрендә Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлегенең Тимерче авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 14 сәгать 00 минутка билгеләргә. Җыенны үткәрү адресы: ТР, Биектау районы, Тимерче авылы, Баш урам, 9 нчы йорт каршында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мулма авыл җирлегенең Тимерче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

- Тимерче авылына керү юлларын һәм вак ташларны сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Мүлмә авыл җирлеге башлыгы Л.Р. Зиннәтуллин